РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» декабрь 2019 ел Олы Кайбыч ав. № 203

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерация-сенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 август-тындагы 340-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Россия Федерациясендә торак фондын хосусыйлаштыру турында» Россия Федерациясе Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 20 декабрен-дәге 399-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның го-муми принциплары турында» Федераль законга шәһәр, авыл җирлегенең, му-ниципаль районның, шәһәр округының, шәһәр эчендәге бүленеше булган шәһәр округының, шәһәр эчендәге районның җирле үзидарә органнарының кулланучы-лар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыруга хокукы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль учреждениеләре төрен үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 13 апрелендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә:

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) оештыруны оештыра;

- муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыра (балаларны өстәмә укытудан тыш, аларны финанс ягыннан тәэмин итүне Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте органнары гамәлгә ашыра);
- муниципаль белем бирү оешмаларын төзи, яңадан оештыра, юкка чыгара (муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмалары төзелүдән тыш);

- муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара;

- муниципаль мәгариф оешмаларының биналарын һәм корылмаларын тотуны, аларга якын территорияләрне төзекләндерүне тәэмин итә;

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә ала, муниципаль мәгариф оешмаларын муниципаль районның конкрет территорияләренә беркетә;

- төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында укучыларны муниципаль район составына керүче җирлекләр арасында бушлай йөртүне оештыра;

- гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә Район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыра (халыкка медицина ярдәме күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән территорияләрдән тыш);

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра»;

- инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин